**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дурасово торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 20 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлегенең Дурасово торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Дурасово торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге Дурасово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, сугыш һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Садовая, Центральная, Ягодная, Лесная, Северная урамнарын яктырту буенча техник хезмәт күрсәтү;

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Садовая, Центральная, Ягодная, Лесная, Северная урамнарын карап тоту (юлларны кардан чистарту);.

Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Дурасово авылында зиратны карап тотуны оештыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин урамы, 5 йорт, Дурасовоавылы, Үзәк урам 50 йорт (авыл мәдәният йорты) адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый

актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов